# ВАЖАШУР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

25 март 2021 ел №5

2018 елның 27 апрелендәге 9 номерлы Важашур авыл җирлеге Советы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 юнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне гамәлдәге кануннарга туры китерү максатларында Важашур авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. 2018 елның 27 апрелендәге 9 номерлы Важашур авыл җирлеге Советы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Важашур авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Важашур авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 ноябрендәге 24 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 10 номерлы, 2020 елның 20 мартындагы 7 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 бүлекнең 20 пунктында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «(булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

2) 12 бүлекнең 1.3 пунктындагы 4 пунктчасында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

3) 20 бүлекнең 9 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, шулай ук кирәк булганда муниципаль хезмәт стажын раслый торган һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 30 нчы статьясында күрсәтелгән башка документларның күчермәләре;»

4) 20 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 16.1 пункт өстәргә:

«16.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмаганда башкарыла.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү турында мөрәҗәгать иткән көннән алып 90 көн эчендә җайга салынганда тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү мондый билгеләнеш өчен мөрәҗәгать иткән көннән алып башкарыла.»

5) 25 бүлекнең 1 пунктындагы 4 пунктчасында «(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр булдыру һәм һәм күрсәтелгән белешмәләрне Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру» сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Җирлек башлыгы: П.Л.Иванов